I. 1.) сүзе үтә торган - хөрмәтле
2.) шалкан бәясе - очсыз
3.) ике йөзле - ялагай
4.) ачык авыз - игътибарсыз
5.) салкын күңелле - кырыс
6.) җиңел сөякле - җитез, булдыклы
7.) олы җанлы - мәрхәмәтле, кешелекле
8.) кош теле хәтле - кечкенә
9.) ачык йөзле - эчкерсез, көләч
10.) балтасы суга төшкән - боегу.

II. Бирелгән мисалларда сүз уйнату анаграммага нигезләнгән. Анаграмма - ул сүздәге хәрефләрнең урыннын алыштыру нәтиҗәсендә яңа сүз барлыкка килү.
ташы - шыта - нинди дә булса орлыкның шытым чыгаруы.
мәл - ләм - елга, күл, буа төпләрендәге утырма, ләте.
кисә - сәке - элеккеге өйләрдә калын такталардан җыелган утыру һәм яту урыны (биеклеге якынча ярты метр булган).
тамак - макта - кемгә дә булса яхшы эше, гамәле өчен матур сүзләр әйтү.
тарак - карат
кабат - табак

III. Үз - билгеле алмашлыгы, тамыр сүз, баш килештә, берлек санда.
Ялдына - бәйлек сүз, үз алмашлыгына иярә килә, II зат тартым белән төрләнгән, юнәлеш килешендә.
Куйган - сыйфат фигыль, затланышсыз, үткән заманда, барлыкта, төп юнәлештә, тамыр сүз.
Максатны - уртаклык исем, тамыр сүз, берлек санда, тартым белән төрләнмәгән, төшем килешендә.
Тормышка - уртаклык исем, тамыр сүз, берлек санда, тартым белән төрләнмәгән, юнәлеш килешендә.
Ашыруга - исем фигыль, затланышсыз, барлыкта, төп юнәлештә, берлек санда, тартым белән төрләнмәгән, юнәлеш килештә.
Иртәгә - вакыт рәвеше, тамыр сүз.
Тотынырмын - хикәя фигыль, I зат, берлек санда, билгесез киләчәк заман, төп юнәлештә.

Дип - әйтелек сүз.
Уйлама - боерык фигыль, II затта, берлек санда, юклыкта, төп юнәлештә, тамыр сүз.

IV. 1 - ж   6 - г
2 - д   7 - б
3 - д   8 - е
4 - и   9 - з
5 - а   10 - в

V. Душа в пятки ушла - кот очу, коты ботына киткән.
Держать в ежовых рукавицах - каты кулда тоту.
Толочь воду в ступе - иләк белән су ташу.
Кожа да кости - тире дә сөяк.
Втирать очки - кәкре каенга терәтү, күз буяу.

VI. Бозлавык - кояшлы һәм кышкы вакытларда һава температурасының башта күтәрелүе, аннан түбәнәюе нәтиҗәсендә җир өстенең боз кабыгы белән каплануы.
Бозлы, бозлык.

VII. Татар теленең лексикасы бик бай. Лексика дип теге яки бу телнең сүзләр җыелмасын атыйлар. Сүзнең лексик мәгънәсе дип сүздә предмет, билге, эш-хәл, мөнәсәбәт, чагылышын атыйлар.

Теленең сүзлек составында бер генә мәгънәгә һәм берничә мәгънәгә ия булган сүзләр аерылып тора. Бер мәгънәле сүзләр - сүзнең бер генә лексик мәгънәгә ия булган сүзләр. Күп мәгънәле сүзләр - сүзнең ике яки аннан да артык лексик мәгънәле булуы.

Күпмәгънәлелек күренеше полисемия дип атала. Татар телендәге сүзләрнең абсолют күпчелеге - күп мәгънәле. Күпмәгънәлелек аркасында күчерелмә мәгънә барлыкка килә. Күчерелмә мәгънәләрнең түбәндәге төрләре мәгълүм:
1. Метафора - бер предмет атамасының охшашлык нигезендә икенче бер предметка күчүе: тау башы, ак күңел һ.б.
2. Метонимия - ике әйбернең янәшә булуы нигезендә барлыкка килгән күчерелмә мәгънә: зал елый, Тукайны укыйм һ.б.

3. Синекдоха – сүз мәгънәсен бөтеннән өлешкә, өлештән бөтенгә күчерү: шикәр алып кайту, урман кисү һ.б.

Сүзнең күчерелмә мәгънәләре сөйләмне җанландыруда һәм гомумән „образлы тел" тудыруда әһәмиятле роль уйный. Без сөйләмебездә күчмә мәгънәле сүзләрне һәрвакыт кулланабыз. Алар безнең сөйләмне төрләндерә, фикерләребезне тирән һәм үтемле итеп җиткерергә ярдәм итә.

Мисаллар: җылы көн, җылы караш; кара балчык, кара көн, кара фикер; алтын йөзек, алтын күз, алтын кеше, алтын сүз; каты су, каты җир, каты колак, каты елау.

VIII. Сүзләр! Сүзләр! Бу дөньяда яши-яши без сүзләрнең мәгънәсен чын-чынлап аңлый башлыйбыз. Ин беренче чиратта, ул - аралашу коралы. Кешенең акыл-зирәк матурлыгы аның сүзләрендә күренә. Халыкта: „Кеше күрке йөз булыр, йөзнең күрке күз булыр, телнең күрке сүз булыр" дигән мәкаль бар. Чыннан да, яхшы сүз кешеләрнең күңелен күтәрә, авырлыкларны җиңәргә көч бирә. Ямьсез сүз изге хисләрне үтерә, кешенең кулыннан эше төшә, үкенечләргә китереп тери.

Әйе, сүзнең көче зур. Бөек Ватан сугышы елларында шигырь сүзе утлы коралга әйләнгән. Шигырь сүзе дә бу чорда туган җиргә булган нечкә хисләрне дә, дошманга булган нәфрәтне дә белдергән. Шагыйрьләребез М. Җәлил, Ф. Кәрим үз шигырьләре белән сугышчыларны дошманга каршы рәхимсез көрәшергә дәртләндергән, җиңүгә ышаныч уяткан, үз артыннан батырлыкка өндәгән:

„Бөек җыр ул - Бөек Ватан өчен
Сугыш кырларында үлүе," - дип яза Ф. Кәрим әсәрендә. Үлем-җыр! Чын күңелдән әйтелгән йөрәк сүзе!

Сүзләр бүген дә үзенең тылсымлы көчен югалтмый. Сүзләргә дөнья йогыйоклана. Алар - тере, алар яши, алар зур көчкә ия. Без сүзгә сакчыл булырга, аның көчен тоярга, аңа ышанырга тиешбез. Чөнки кеше туганда да, борчу-

шатлык килгәндә дә, яуга күтәрелгәндә дә, кадер-
лесен иркәләгәндә дә иң мөһим сүзләрне ~~[illegible]~~ әйтә.
Һәрбер сүз дөньяга ямь алып килә.

„Тел белән сөйләнә кешенең сүзе,
Сүз яхшы булса, нурлана йөзе",

дип язган Й. Баласагунлы. Сөйләгән сүзләребез як-
ты, гамәлләребез изге, йөзләребез нурлы булсын!